Республика Татарстан
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ МУРТЫШ-
ТАМАКСКОГО
СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯСАРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Татарстан Республикасы САРМАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОННЫҢ
МОРТЫШТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ

БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

# КАРАР

25.01.2016 ел № 4

Мортыштамак ав.

Референдум уздыруны инициацияләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, Мортыштамак авыл җирлегенең 11 ст. нигезендә Сарман муниципаль районының Мортыштамак авыл җирлеге советы КАРАР ИТӘ:

1. Җирле референдум уздыруны түбәндәге сорау буенча инициацияләргә: 2015 елда Мортыштамак авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән I төркем инвалидлардан, көндезге бүлек студентларыннан башка балигъ булган һәр кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә 200 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы:

- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү;

- җирлек территориясендә физик культураны һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, җирлекнең рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;

Җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял итү өчен шартлар тудыру

җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (урамнарны яктыртуны, территорияне яшелләндерүне, урамнарның исемнәре һәм йортларның номерлары белән күрсәткечләр урнаштыруны, кече архитектура формаларын урнаштыруны да кертеп);

- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;

- ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту

- җирлектә балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру;

- җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы гражданнарга һәм аларның берләшмәләренә халык дружиналары эшчәнлеге өчен шартлар тудыру;

- каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым җыю) һәм транспортировкалау эшчәнлеген оештыруда катнашу;

-җирлек чикләрендә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, суны чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру;

-җирлек халкының күпләп ял итүе өчен шартлар тудыру һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру, моңа гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр полосаларына иркле керүен тәэмин итү дә керә.

«ӘЙЕ» «ЮК»

Сарман муниципаль районы

Мортыштамак авыл җирлеге

Совет Рәисе: Әхмәтгәрәев М.Н